ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09 декабрь 2025 ел № 10311

Башкарма комитетның «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасы турында» 2022 елның 25 октябрендәге 5773 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Уставы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасы турында» 2022 елның 25 октябрендәге 5773 номерлы Карарына (Башкарма комитетның 2023 елның 31 мартындагы 2595 номерлы, 2023 елның 16 ноябрендәге 11212 номерлы, 2024 елның 16 февралендәге 1006 номерлы, 2024 елның 4 апрелендәге 2155 номерлы, 2024 елның 20 августындагы 5454 номерлы, 2024 елның 9 октябрендәге 6582 номерлы, 2024 елның 4 декабрендәге 8116 номерлы, 2025 елның 14 мартындагы 1977 номерлы, 2025 елның 1 июлендәге 4812 номерлы, 2025 елның 22 августындагы 6179 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә муниципаль программа чараларын финанслауны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында каралган акчалар хисабына 812 349,48 мең сум күләмендә тәэмин итәргә: 2023 ел – 227 547,29 мең сум; 2024 ел – 259 724,78 мең сум; 2025 ел – 325 077,41 мең сум.»;

2) 2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасында:

- 1 бүлектә «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2023 ел (мең сум) | 2024 ел (мең сум) | 2025 ел (мең сум) | Тормышка ашыру чорында барлыгы (мең сум) |
| | Муниципаль бюджет | 227 547,29 | 259 724,78 | 325 077,41 | 812 349,48 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Федераль бюджет | - | - | - | - |
| | Республика бюджеты | - | - | - | - |
| | Башка чыганаклар | - | - | - | -»; |

- 4 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

2023-2025 елларга программаны финанслау күләме 812 349,48 мең сум тәшкил итә.

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.

Чор өчен барлыгы 812 349,48 мең сум, шул исәптән программаны тормышка ашыру еллары буенча:

2023 ел – 227 547,29 мең сум;

2024 ел – 259 724,78 мең сум;

2025 ел – 325 077,41 мең сум.»;

3) 6 бүлекнең 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 9. | Татарстан Республикасы һәм Яр Чаллы шәһәре үсешенә зур өлеш керткән гражданнарны, Мактаулы гражданнарны җирләү чараларын үткәрү | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | Ел дәвамында | Кеше саны | 1 | 2 | 2 | 2 | 160,00 | 310,00 | 1500,00 |

4) 6 бүлекнең 27 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «27. | Мунча хезмәтләре күрсәтү | Башкарма комитетның торак-коммуналь хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | Ел дәвамында | Күрсәтелгән хезмәтләр саны | 54 442 | 54 442 | 54 442 | 54 442 | 5187,18 | 5 110,01 | 6 398,68»; |

5) 6 бүлекнең 29 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «29. | Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларның туклануын тәэмин итү | Башкарма комитет | Ел дәвамында | Балалар саны | - | 35180 | 35180 | 35180 | 66 082,00 | 74 458,20 | 86 220,40»; |

6) 6 бүлекнең БАРЛЫГЫ юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| БАРЛЫГЫ: | 227 547,29 | 259 724,78 | 325 077,41. |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов